**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**САТМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

**1 август 2018 ел** **№9**

**Күчемсез милек объектына адрес бирү (үзгәртү, аныклау, бетерү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Сатмыш авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Сатмыш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Күчемсез милек объектына адрес бирү (үзгәртү, аныклау, бетерү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 18 ноябрендәге 11 нчы карары белән расланган күчемсез милек объектына адрес бирү (үзгәртү, аныклау, бетерү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«5.Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның яисә аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү**

5.1.Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы җирлек Башкарма комитеты хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) җирлек Башкарма комитетытына яки муниципаль берәмлек Советына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1)муниципаль хезмәт күрсәтүне сорауны, "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән сорауны теркәү вакытын бозу;

2)муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә күп функцияле үзәккә йөкләнгән очракта мөмкин.";

3)муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар таләп итү;

4)мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту, әгәр дә баш тарту нигезе федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган очракта. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә күп функцияле үзәккә йөкләнгән очракта мөмкин."

6)муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән күздә тотылмаган түләү алу;

7)муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең,

күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның яисә аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хатаны төзәтүдән баш тарту яисә төзәтмәләр кертү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә күп функцияле үзәккә йөкләнгән очракта мөмкин."

8)муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр дә туктатып тору нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган очракта. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә күп функцияле үзәккә йөкләнгән очракта мөмкин."

5.2. Шикаять кәгазьдә яки электрон формада язмача авыл җирлеге башкарма комитетына бирелә.

Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтын (http://apastovo.tatarstan.ru), күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтын, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталының рәсми сайтын (http://uslugi.tatar.ru/), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/) кулланып күпфункцияле үзәк аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

5.3.Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең оештыручысына, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга

яисә югары органга (булганда) кергән шикаять теркәлгән көннән унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдән яки җибәрелгән хаталарны төзәтүдән муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, күпфункцияле үзәкнең, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның баш тартуына шикаять китергән очракта теркәлгән көннән биш эш көне эчендә.»;

5.4. Шикаятьтә булырга тиеш:

1) кем өстеннән шикаять китерелә шул муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмзткәрләренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең –физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүченең – юридик затның яисә атамасы, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның яисә аларның хезмәткәрләренең шикаять китерелә торган карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулыры) турында мәгълүматлар;

4) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларның яисә аларның хезмәткәрләренең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулыры) белән мөрәҗәгать итүченең риза булмау дәлилләре. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5.Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре куелырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6.Шикаять шикаятьне бирүче муниципаль хезмәт алучы тарафыннан имзалана.

5.7.Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1)шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә дә;

2)шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту.

5.8.Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яисә җинаять билгеләре билгеләнгән очракта "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясының 1 өлеше нигезендә шикаять карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллыйлар.

5.9. Шикаятьне тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, җитешсезлекләрне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чаралар билгеләнә.

5.10. Авыл җирлеге башкарма комитетыгың, аның вазыйфаи затларының, шулай ук күпфункцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) мөрәҗәгать итүчеләр Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Авыл җирлеге башлыгы урынбасары** **И.Х.Салахов**